ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КАРАЗИРЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

№3 Иске Каразирек ав. 20 февраль 2025 ел

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

2002 елның 12 июнендәге «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында»гы 67-ФЗ санлы Федераль законның 18 маддәсе, 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 25, 26 маддәләре нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 38 маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бер мандатлы сайлау округларының кушымтада бирелә торган схемасын ун елга расларга.

2. Әлеге карарны, бер мандатлы сайлау округлары схемасын да кертеп, аның график сурәте белән бергә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә (https://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://jutaza.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге торак пунктлары территориясендә түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Иске Каразирек авылы, Совет урамы, 12 санлы йорт, администрация бинасы; Яңа Каразирек авылы, Пионерлар урамы, 18 санлы йорт, авыл клубы бинасы.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә

Ютазы муниципаль районы
Иске Каразирек авыл җирлеге башлыгы И.Р.Гәрәев

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Иске Каразирек авыл җирлеге Советының
2025 елның “20” февралендәге
3 санлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бер мандатлы сайлау округлары схемасы**

**1 санлы Иске Каразирек бер мандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 66

Округка Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Иске Каразирек авылы, Ленин урамы, 1-30, 31 санлы йортлар.

**2 санлы Иске Каразирек бер мандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 59

Округка Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Иске Каразирек авылы, Ленин урамы, 30А, 30Б, 32-67 санлы йортлар; Совет урамы, 1-10 санлы йортлар; Горький урамы, 1-11 (так як) санлы йортлар.

**3 санлы Иске Каразирек бер мандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 61

Округка Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Иске Каразирек авылы, Тукай урамы, 21-27 (так як), 30-76 санлы йортлар.

**4 санлы Иске Каразирек бер мандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 62

Округка Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Иске Каразирек авылы, Тукай урамы, 1-20,22-28 (җөп як); Яшьләр урамы, 8-9А санлы йортлар.

**5 санлы Иске Каразирек бер мандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 71

Округка Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Иске Каразирек авылы, Яшьләр урамы, 1-7А санлы йортлар; Горький урамы, 2-12 (җөп як), 12А-33 санлы йортлар.

**6 санлы Иске Каразирек бер мандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 71


Округка Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Яңа Каразирек авылы, Комсомол урамы, 1-34 санлы йортлар; Пионерлар урамы, 18-28 (җөп як) санлы йортлар.

**7 санлы Иске Каразирек бер мандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 71

Округка Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Яңа Каразирек авылы, Комсомол урамы, 36-62 санлы йортлар; Пионерлар урамы, 1-17, 19, 21 санлы йортлар.

Графическое изображение схемы
одномандатных избирательных округов для проведения выборов депутатов
Совета Старокаразерикского сельского поселения Ютазинского муниципального
района Республики Татарстан




Старокаразерикский избирательный округ №1
Старокаразерикский избирательный округ №2
Старокаразерикский избирательный округ №3
Старокаразерикский избирательный округ №4
Старокаразерикский избирательный округ №5
Старокаразерикский избирательный округ №6
Старокаразерикский избирательный округ №7